№ 1 педагогик киңәшмә утырышында каралды
29 августа 2025ел.

Раслыйм
МБМБУ "Югары Симет "Ромашка" балалар бакчасы мөдире
_______ А.А. Шакирова
Приказ№ 60 29 августа 2025ел

# Татарстан Республикасы
# Саба муниципаль районы
# муниципаль бюджет мәктәпкәчә
# белем учреждениесе Югары Симет
# "Ромашка" балалар бакчасының
# 2025-2026 нче уку елына
# Тематик планы

| № | Т е м а | В а к ы т ы | Истәлекле даталар | М а к с ат | Йомгаклау |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | **Белембәйрәме** | 1 – 6 сентябрь | 1 сентябрь – Белем көне<br>3 сентябрь-Икенче бөтендөнья сугышы тәмамлану көне | Балаларда мәктәп турында уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.Мәктәпкә бару теләген формалаштыру.Укучы, укытучы, дәрес, тәнәфес сүзләре белән таныштыру. | Белем бәйрәме. |
| 2 | **Минем бакчам.Балалар бакчасыныңурыны һәм исеме белән танышу.** | 8 – 13 сентябрь | 8 сентябрь – Халыкаграграмоталылыкны тарату көне.<br>9 сентябрь-Бөтен дөнья беренче ярдәм күрсәтү көне.<br>9 сентябрь-бөек рус язучысы Лев Николаевич Толстойныңтуган көне (1828 - 1910)<br>13 сентябрь - Россияда парикмахер көне | Балаларның җәйге яллардан сон бакчада җыелу, очрашу, шатлыклы мизгеләләрен бүлешү. Балалар бакчасына карата ярату хисләре тәрбияләү.Җәйге күңелле вакыйгаларны искә төшерү, балаларның сөйли белү сәләтен үстерү. Хезмәткәрләр белән әңгәмә кору, Әйләнә- тирәне барлау, уенчыклар белән уйнау, сак караш тәрбияләү<br>«Минем бакчам» дигән темага хикәя төзеп сөйләргә өйрәтү. | “Минем бакчам”-рәсем күргәзмәсе |
| 3 | **Туган Татарстаным.** | 15 – 20 сентябрь | 17 сентябрь- рус галиме, язучы Константин Эдуардович Циолковскийның (1857 - 1935)туган көне.<br>19 сентябрь – смайлик көне. | Балаларда күзаллаулар булдыру: Татарстан – күпмилләтле республика; Казан – республиканың һәм бөтендөнья татарларының башкаласы; Татарстан Республикасының төп символикасы (флаг, герб, гимн) белән таныштыру; балаларга үз халкыңның бер өлеше булуларын аңлату; ТР ның географик урыны белән таныштыру (картада яки глобуста республиканың территориясен, Кама, Идел елгаларын, Куйбышев, Түбән Кама сусаклагычларын, Кабан күлен, тирә-як күл һәм елгаларын билгеләү);Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның традицияләре, гореф-гадәтләре, йолалары белән таныштыру; милли бәйрәмнәр (Нәүрүз, Корбан бәйрәме, Сабантуй, Нардуган һ.б.) турында күзаллаулар булдыру; башка милләтләргә карата хөрмәт һәм дусларча мөнәсәбәт тәрбияләү;әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге күренекле эшлекле- ләрнең ( шагыйрьләр:Г.Тукай, | Туган якны өйрәнү сәгате “Татарстан минем республикам ” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | М.Җәлил, Р.Миңнуллин һ.б., язучылар: А.Алиш, Р.Батулла һ.б., рәссамнар: Х.Якупов, Х.Казаков һ.б., скульптор Б.Урманче һ.б.) тормыш һәм иҗатлары белән таныштыру, аларның тормышлары һәм эшчәнлекләренә карата кызыксыну уяту;туган җирең, халкың,телең белән горурлану хисе тәрбияләү, Татарстанда яшәгән башка халыкларның мәдәниятен хөрмәтләү. | |
| 4 | **Мониторинг.Сабам минем-туган ягым.** | 22 – 27 сентябрь | 21 сентябрь-шагыйрь һәм язучы Сергей Александрович Есенинның туган көне (1895 – 1925)<br>25 сентябрь-Бөтен дөнья диңгез көне<br>27 сентябрь-тәрбияче һәм барлык мәктәпкәчә хезмәткәрләр көне. | Туган якка мәхәббәт тәрбияләү. Район атама-сының каян килеп чыгышы турындагы леген-далар белән таныштыру. Хәзерге район турында күзаллау формалаштыру. Җитәкчеләр, районда-гы биналар, урамнар белән танышу. Район халкының кунакчыллыгына соклану, андагы традицияләр, гореф- гадәтләр турында сөйләү. | «Туган ягым Саба төбәге" презентация карау |
| 5 | **Ел фасыллары. "Исәнме, Алтын көз!" Календарь( мәт)** | 29– 4 октябрь | 1 октябрь-Халыкара өлкәннәр көне;Халык-ара музыка көне.<br>4 октябрь-Хайваннарны яклау көне<br>5 октябрь-Укытучылар көне | Көз фасылының үзенә генә хас булган матурлыгын һәм гүзәллеген күрә белергә өйрәтү, соклану хисләре тәрбияләү. Балаларда көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксынучанлык сыйфатлары тәрбияләү.<br>Үзләштерелгән сүзлек запасына таянып, агач, яфрак, үләннәрне, һава торышын тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен үстерү. | Көзге паркка экскурсия.<br><br>Көзге яфраклар-коллектив белән эш |
| 6 | **Көз күчтәнәчләре**<br><br>**Яшелчә, җиләк җимеш, гомбә.** | 6 – 11 октябрь | | Яшелчәләр турындагы белемнәрен система-лаштыру, көзен яшелчә,җиләк- җимешләрдән мул уңыш өлгерүен, аларны тышкы күренешләре буенча танып белү,аларның файдалы үзлекләрен аңларга булышу файдалы һәм зарарлы ризыклар турында алган белемнәрен уеннар барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү. Культура гигиеник күнекмәләр формалаштыру. | "Көзге муллык безнең өстәлдә"- күргәзмә. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7 | **Табигый бергәлекләр. Сулыклар.** | 13 – 18 октябрь | 15 октябрь – Россиядә әтиләр көне.<br>16 октябрь -Бөтен дөнья икмәк көне. | Балаларның сулыклар турында табигый бергәлек буларак күзаллауларын формалаштыру, сулыктагы барлык үсемлекләр һәм хайваннар билгеле бер экологик нишаны биләп торулары һәм бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә булуларын аңлату. Балаларда табигатькә мәхәббәт, аңа сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү. | Күлгә экскурсия. |
| 8 | **Ашамлыклар. Икмәк – яшәү терәге. Авыл хуҗалыгы культуралары** | 20-25 октябрь | 25 октябрь: Халыкара мәктәп китапханәләре көне<br>28 октябрь- халыкара анимация көне | Авыл хуҗалыгы хезмәткәре һөнәре белән якыннан танышу. Балаларга икмәкнең һәр көн куллана торган ризык икәнен, икмәк ризыкларының куп төрле булуын аңлату.Кырларда үскән икмәкнең өстәлгә килгәнче зур юллар үтүен, аңларга булышу. Ипигә, игенче хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.<br>Табышмаклар ярдәмендә күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү. Яңа очраган сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, сүзлек запасын баету, игенче хезмәтенең авыр һәм мактаулы эш икәнен аңлату. | “Икмәк илебезнең байлыгы” (Әти-әниләрнең тозлы камырдан ясалган эшләреннән күргәзмә) |
| 9 | **Россия- зур дәүләт. Халыклар бердәмлеге.**<br><br>**Илләр, континентлар(мәт)** | 27 октябрь – 1 ноябрь | | Балаларга Россия символикасы турында мәгълүмат бирү,Россия башкаласы Мәскәү, рус милләте турындагы белемнәрен баету;<br>балаларда туган илне ярату, аның белән кызыксыну, туган илгә тугрылык сыйфатлары, башка милләт вәкилләренә карата хөрмәт, дуслык хисләре тәрбияләү.<br>Илләр континентлар белән таныштыу. | Чара”Россия-зур дәүләт”. |
| 10 | **Йорт хайваннары һәм кошлары.** | 3 – 8 ноябрь | 3 ноябрь- шагыйрь, драматург Самуил Яковлевич Маршакның туган көне (1887 - 1964)<br>4 ноябрь- Халыклар бердәмлеге көне<br>6 ноябрь- Татарстан РеспубликасыКонституциясе көне<br>6 ноябрь- язучы, | Балаларда йорт хайваннарына һәм кошларына карата кызыксыну үстерү,яшәү рәвешләре турындагы белемнәрен баету һәм сакчыл караш тәрбияләү. | Әкият кичәсе “Әкияттә кунакта”(йорт хайваннары һәм кошлары турында әкиятләрне сәхнәләштерү). |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | драматург Дмитрий Наркисович Мамин-Сибирякның (1852-1912)туган көне. | | |
| 11 | **Кыргый хайваннар тормышы. Табигаттәге бәйләнеш, (туклану чылбыры (мәт))** | 10 – 15 ноябрь | 14 ноябрь - Халыкара логопед көне | Балаларда кыргый хайваннарга карата кайгыртучанлык һәм кызыксыну үстерү, табигать бәйләнешләр турындагы белемнәрен баету һәм сакчыл караш тәрбияләү. Балалары, аларның тышкы билгеләре,яшәү рәвешләре белән таныштыру. | Интеллектуаль уен“Кыргый хайваннар”. |
| 12 | **Әниләр көне.** | 17 – 22 ноябрь | | Әниләр көне уңаеннан балаларда күтәренке кәеф булдыру, балалар эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә хатын-кыз, ана темасын яктырту. Әниләргә хөрмәт тәрбияләү, гаиләдә эти кешенең хатын- кызларга, әниләргә хөрмәте турында кузаллау булдыру. Әниләргә кулдан эшләнмәләр әзерләү. | “Әнием минем бергенәм!”-әниләр катнашында бәйрәм кичәсе. |
| 13 | **Күчмә һәм кышлаучы кошлар** | 24-29 ноябрь | 27 ноябрь-Рәссәйдә әниләр көне<br>30 ноябрь-Россия Федерациясе дәүләт гербы көне | Балаларда кошларга сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. Чагыштыру, күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык күнекмәләрен үстерү. Балаларныңкошлартурындабелемнәренбаету, өлкәннәр ярдәмендәҗимлекләркуяргаөйрәтү. | “Кошлар” операциясе - кошларга җимлек кую |
| 14 | **Салкын кыш. Кышкы табигать үзгәрешләре Табигать бәйләнешләре, табигать күренешләре (мәт)** | 1–6декабрь | 3 декабря – Билгесез солдат көне.Халыкара инвалидлар көне<br>5 декабрь- Россиядә ирекле(Волонтер) көне | Кыш, кар үзенчәлекләре турында балаларның белемнәрен тирәнәйтү; табигатьтә ел фасыллары буенча барган үзгәрешләр турындагы белемнәрен системалаштыру; кышкы табигатькә хас билгеләр турындагы белемнәрне ныгыту;җәнлекләрнең, кошларның кышка ничек җайлашуы турындагы белемнәрне арттыру;кышкы салкын көннәрнең кошлар, хайваннар, кешеләр өчен иң авыр вакыт булуын ачыклау;балаларны әдәби әсәр аша кышның тасвирланышы белән таныштыру; серле табигать күренешләренә соклану хисләре һәм мәхәббәт уяту; балаларда шигырь юллары аша кышкы табигатькә соклану хисләре, мәхәббәт тәрбияләү;табигатькә сак караш, экологик бәйләнешләрне күрә белү сыйфаты тәрбияләү. | Җыр кичәсе“Беренче кар”. |
| 15 | **Сәнгатьатналыгы. Балалар язучылары,** | 8 – 13 декабрь | 8 декабрь-халыкара | Татар язучыларының тормышюлы, иҗаты белән таныштыру. Аларның әсәрләре ничек итеп яхшыны яманны күрә белергә , | А.Алишның “Куян кызы” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **шагыйрләреһәм рәссамнарыиҗаты. (А.Алиш, Р.Миңнуллин һ.б.)** | | рәссамнар көне<br>9 декабрь-Ватан Геройлары көне<br>12 декабрь-Россия Федерациясе Конституциясе көне, композитор, музыка педагогы Владимир Яковлевич Шаинскийның туган көне (1925-2017) | хезмәт сөяргә, олыларны хөрмәт итәргәөйрәтүен ассызыклау. Әкияткә сәнгәть әсәре буларак тотрыклы кызыксынуны тәэмин итү, үстерү. Сөйләм теле камил, белемле шәхес тәрбияләү.Матур әдәби телдә сөйләшергә өйрәтү | әкиятенә рәсем ясау конкурсы. |
| 16 | **Таулар.Тау токымнары һәм минераллар. Файдалы казылмалар (мэт)** | 15 – 20 декабрь | 15 декабрь-йомшак уенчыклар көне | Балаларның таулар турында беренче күзаллауларын формалаштыру.Тау токымнары һәм минераллар төрлелеге,аларның үзлекләре белән таныштыру. Файдалы казылмалар турында күзаллау формалаштыру, файдалы казылмалар булганын өйрәтү. | “Тау токымнары”-күргәзмәсе |
| 17 | **Кышкы могҗизалар.Яңа ел бәйрәме бүләкләре,символлары. Туган якта һәм башка илләрдә Яңа ел каршылау гореф-гадәтләре.Хуш киләсең, яңа ел!** | 22 – 27 декабрь | 27 декабрь-Третьяков галереясына нигез салучы Павел Михайлович Третьяковның (1832-1898)туган көне.<br>31 декабрь- Яңа ел | Балаларда күтәренке кәеф, шатлык хисләребулдыру;күңел ачуларда катнашасы килү теләге уяту;балаларны күңел ачуларга хәзерлек эшләрендә катнаштыру, бергәләп эшләгән эш нәтиҗәләрен күреп сөенү.<br>Яңа ел бәйрәме, аңа бездә һәм башка илләрдә ничек әзерләнүләре, нинди әкият геройлары килүе, Кыш бабай, Кар кызы турында күзаллауларны киңәйтү; балаларда бәйрәмнәргә карата уңай мөнәсәбәт, үз фикереңне бер юнәлештә туплый һәм аны башкаларга җиткерә белү сыйфаты тәрбияләү.<br>Балалардабәйрәмнәргә карата уңай мөнәсәбәт,үз фикереңне бер юнәлештә туплый һәм аны башкаларга җиткерә белү сыйфаты тәрбияләү.Бәйләнешле сөйләм телен,иҗади күзаллауларын үстерү.Балаларда үз тәҗрибәсеннән чыгып бәйрәм турында әйтә алу мөмкинлекләрен камилләштерү. | Бәйрәм иртәсе”Яңа ел сәяхәте”. |
| 18 | **Хезмәт төбе- хәзинә. Ресурсларны икенчел куллану.** | 29-31 декабрь<br>9 – 10январь | 12 январь-кайнарчәйкөне. | Балаларның өлкәннәр хезмәте, аларның һөнәрләре турында белемнәрен киңәйтү, алар хезмәтенең мөһимлеген аңлату;төрле һөнәр ияләренә карата кызыксынучанлыкларын үстерү;балаларда һөнәр осталарының матур эшләренә соклану, аларның хезмәтенә хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләү.Балаларны, кешеләрдәгекебекүк, предметларның да үзүткәне, бүгенгесеһәмкиләчәге бар | Хезмәт турында эндәшләр, тизәйткечләр, әйтемнәр, сынамышлар |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | дигәннәтиҗәгәкитерергә. | бәйгесе. |
| 19 | **Минем гайләм,өем, йорт җиһазлары. Техник прогресс. Заманча йортлар, корылмалар.** | 12 –17 январь | 13 январь- ИскеЯңа ел Раштуабәйрәме | Балаларда гаилә әгъзаларына карата ихтирамлы мөнәсәбәт,йорт җиһазларына сакчыл караш тәрбияләү.Балаларның йорт җиһазлары турындагы белемнәрен баету,тирәнәйтү, мөстәкыйль һәм гомумиләштереп фикерләү сәләтен үстерү.Кеше кулы белән эшләнгән әйберләргә карап соклана,хезмәт нәтиҗәләрен күреп горурлана белү хисләре тәрбияләү,электр җиһазларын кулланганда сак булырга өйрәтү.Балаларның фикерләрен бер юнәлештә туплый белү, алган белемнәрен көнкүрештә куллана белү сәләтен үстерү.Эш урынында кешенең хезмәтен җиңеләйтүче, өйдә кеше өчен уңайлыклар тудыручы предметлар турында белемнәрен камилләштерү.Гаиләдә бер-берсенә игътибарлылык, ярдәмләшү һәм дуслык, үзара хөрмәт хисләре тәрбияләү. | Күргәзмә “Гайлә агачы”. |
| 20 | **Халык сәнгате.Киемнәр дә безне бизиләр. Милли культуралары, традицияләре,Милли бәйрәмнәр.** | 19 – 24 январь | 25 гыйнвар- Россия студентлары көне . | Балаларда киемнәргә карата зәвык, сакчыл караш тәрбияләү. Тәрбияче биргән сорау-ларга төгәл җавап кайтара белүкүнекмәсен үстерү. Тормышта тышкы кыяфәтнең дә мөһимлеген аңлауларына ирешү; өс-баш, аяк киемнәрен чагыштырырга, төркемнәргә аерырга өйрәтү.Балаларда исәнләшү, саубуллашу,ясле- бакча хезмәткәрләрен исеме, әтисенең исеме беләнәйтергә күнектерү. Үтенечнңне әдәпле генә итеп белдерә алу, олылар сүзенә катышмау. сораган хезмәт өчен рәхмәтле була белү кунекмәләре тәрбияләү. | “Түбәтәй һәм калфак бизәү”(балаларның кул эшләреннән күргәзмә). |
| 21 | **Җирдә мин кеше! Мин шәхес.Минем хокукларым.** | 26 январь - 31 январь | 27 гыйнвар- Ленинградны фашист блокадасыннан тулысынча азат итү көне. Холокоста корбаннары көне | Балаларның гаиләдәге хокуклары турындагы белемнәрен ныгыту, аларның ялга, уенга хокуклы булуларын аңлату; кеше бер-берсе белән, нинди милләттән булуына карамастан, туганнарча аралашып яшәүгә хокуклы булу төшенчәсен бирү;бар кеше дә яхшы тормышка хокуклы, җирдәге тынычлык кешеләрнең үзләреннән тора, бар халыклар да аңлашып, ирекле, тигез хокуклы булып, бер-берсе белән дус булып, аралашып яшәргә тиеш төшенчәләрен аңлауларына ирешү. | Чара “Минем исемем”. |
| 22 | **Юлларда иминлек кирәк.Транспорт.Заман** | 2– 7 февраль | 2 февраль- 1943 елда Сталинград | Урамда, җәмәгать транспортында, торак зонасында үз-үзеңне тоту культурасын тәрбияләү. Юлларда күзәтүчәнлекне, фикерләү | Юл йөрү кагыйдәләре |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | **ча транспорт(мэт) Транспорт хезмәткәрләре.** | | сугышында СССР Кораллы көчләренең Гитлер Германиясе армиясен Җиңү көне .<br>4 февраль- балалар шагыйрәсе, язучы, киносценарист, радио алып баручы Агния Львовна Бартоның туган көне (1901 1981)<br>8 февраль- Россия Фән көне. | мөстәкыйльлеген,дикъкатьлелекне үстерү. Юл билгеләрен аера белү, юлда хәвефсез тоту кагыйдәләрен өйрәтү.Балаларда транспорт йөртүче һөнәр ияләренә карата хөрмәт,ихтирам һәм урамда,транспортта үз-үзләрен дөрес тоту сыйфатлары тәрбияләү.Коры җир,су һәм һава транспорты чараларын аера белергә,аларны чагыштырырга,төркемнәргә аерырга өйрәтүне дәвам итү,һәр төр транспорт турындагы күзаллауларын киңәйтү. | буенча тәрбияви чара“Яшел ут”. |
| 23 | **Халыкара телләр көне.М. Җәлил – халык улы..<br>Халык кәсепләре** | 9 – 14 февраль | 15 февраль-Муса Җәлилнең туган көне. | Балаларда төрле милләт халыкларына хөрмәт, дуслык хисләре тәрбияләү. Идел буе халыклары турында, аларның кәсепләре турында балаларның белемнәрен баету.М.Җәлил турында балаларның белемнәрен баету, аның әсәрләре белән танышуны дәвам итү;герой-шагыйрьгә карата бәяләмә бирү, аның батырлыгына соклану хисләре тәрбияләү; балаларда патриотик хисләр, Ватанны саклау теләге тәрбияләү. | “Муса Җәлил-балалар дусты” - музыкаль чара |
| 24 | **Батырлыкта-матурлык Ватанны саклаучылар көне.<br>Безнең армия.** | 16 – 21 февраль | 21 февраль-Халыкара туган тел көне<br>23 февраль-Ватанны саклаучылар көне | Балаларны Ватанны саклаучылар белән таныштыруны дәвам итү, горурлану хисләре тәрбияләү, илне саклау теләге уяту Россия армиясе турында белемнәрен арттыру.Ватанны саклау авыр , ләкин мактаулы булуын төшендерү.Малайларда кыюлык, батырлык, тәвәкәллек сыйфатлары тәрбияләү,кыз балаларда (ватанны саклаучылар буларак )аларга карата ихтирам тәрбияләү | Котлау открыткалары "Бәйрәм белән әтием!"<br>. |
| 25 | **Әдәплелек дәресләре. Табын янында.<br>Яхшы сүз- җан азыгы.** | 24 февраль -28 февраль | Февральнең ахыргы атнасында – Масленица – | Балаларда савыт-сабага карата сакчыл караш тәрбияләү, күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен,диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү.Савыт-сабалар кибете турында белемнәрен | Тәрбияви чара “Яхшылык җирдә ятмый”. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | традиционный восточнославян ский праздник. | тулыландыру, бер-берсен тыңлый һәм җавапларны тулыландыра белү сыйфаты тәрбияләү.Савыт-сабаны урынлы куллана белергә өйрәтү. Үзеңне әдәпле тоту күнекмәләрен тәрбияләү.Милли ризыклар турындагы белемнәрен тирәнәйтү; балаларны кунакчыл булырга, кунакларга хөрмәт күрсәтергә өйрәтү.<br>Балаларда якыннарына, әти-әниләренә карата кайгыртучанлык,игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү;начар сыйфатларга:дорфалык,үзен генә яратучыларга карата тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү;проблемалы сораулар аша яхшылык, шәфкатьлелек, дуслык турында күзаллау бирү;балаларның көнкүрешкә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен үстерү; матур әдәбият аша балаларның сөйләмендә ягымлы сүзләр куллануларына ирешү;бер-береңә игътибарлылык, ярдәмләшү, дуслык, үзара хөрмәт хисләре тәрбияләү. | |
| 26 | **“Яз килә,яз килә,елмаеп кояш көлә!”<br>Халыкара хатын кызлар көне.** | 2 – 7 март | 3 март- Язучылар көне.<br>8 март-Халыкара хатын-кызлар көне. | Балаларда туган ягыбызда була торган язгы табигать күренешләренә соклану хисләре тәрбияләү;максатчыл күзәтү аша балаларны язгы табигать күре-неше белән таныштыру;табигатьтәге бәйләнешләрне аңлата белү күнекмәләрен камилләштерү.Балаларда әниләргә карата мәхәббәт,ихтирам, хөрмәт хисләре, игътибарлылык тәрбияләү; Әниләргә һәрвакыт ярдәмгә килү, аларга булышу теләге тәрбияләү; Әниләрнең дөньяда иң кадерле, иң газиз кеше икәнен аңлауларына ирешү. | Бәйрәм иртәсе. “Әнием-җылы кочагым” (Балалар иртәсе әти-әниләр катнашында). |
| 27 | **Сулар ага,бозлар китә,кошлар кайта җылы яклардан.** | 9 – 14 март | 13 март- язучы һәм шагыйрь, Россия Федерациясе һәм СССР гимннары авторы Сергей Владимирович Михалкованың (1913 - 2009)туган көне. | Әйләнә-тирә дөньяга эстетик мөнәсәбәт формалаштыру;<br>рәсем буенча табигатьтәге үзгәрешләр турында сөйли белүләренә ирешү;яз турында эндәшләр, тизәйткечләр, әйтенүләр, сынамышлар өйрәтү;балаларда яз турында белемнәрен мөстәкыйль эшчәнлектә иҗади куллана белү күнекмәләрен үстерү; табигатькә карата аңлы караш, экологик культура тәрбияләү.<br>Кошлар турында белемнәрен баету;тышкы билгеләренә карап сыерчык,карга һ.б. кошларны танырга, исемнәрен әйтергә өйрәтү, кешеләрнең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру;балаларның күзәтүчәнлекләрен, кызыксынучан-лыкларын, чагыштыра белү күнекмәләрен үстерү;балаларның тасвирлый белү сәләтен үстерү; балаларда кошларга карата сак караш, мәрхә-мәтлелек, кайгыртучанлык сыйфатлары тәрбияләү. | Интеллектуаль чара “Экологик светофор”. |
| 28 | **Су яшәү чыганагы. Табигаттә су әйләнеше, су хайваннары. Суның әһәмияте(мэт)** | 16 – 21 март | 18 март- Кырымның Русия белән берләшүе көне. | Балаларның су,аның үзенчәлекләре,табигатьтә була торган үзгәрешләр турында белемнәрен киңәйтү;Су хайваннары белән таныштыру, яңгырның каян килеп чыгуын аңлату;гади тәҗрибәләр һәм уеннар аша балаларның су үзенчәлекләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү;яшәү чыганагы булган суга сак караш тәрбияләү;табигатькә | «Тылсымлы су»(эксперемент лар) |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | соклана һәм аның гүзәллеген күрә белергә өйрәтү. | |
| 29 | **Театр. Ял итү өчен җәмәгать урыннары.Үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. Китап киңәшчең синең. Балалар китабы атналыгы** | 23 – 28 март | 27 март- Бөтендөнья театр көне.<br>28 март- язучы Максим Горькийның туган көне (1968 - 1936).<br>. | Театр, концерт залы, цирк һ.б. җәмәгать урыннары турында балаларның белемнәрен киңәйтү; җәмәгать урыннарында үз-үзеңне дөрес тоту кагыйдәләре белән таныштыру;башка кешеләрнең үз-үзләрен тотышын күзәтү, чагыштыру, каршы кую, бәяли белү күнекмәләрен үстерү.<br>Китап, аның кайдан килүе, китапханәче хезмәте турында балаларның белемнәрен киңәйтү; китапханә белән турыдан-туры таныштыру аша балаларда күзәтүчәнлек, игътибарлылык, эзлекле фикерләү сәләтен үстерү;китапханәче һөнәренең мөһимлеген аңлату;китапханәче хезмәтенә карата ихтирам, китапханәдә үз-үзеңне тота белү сыйфатлары тәрбияләү;китап карау, укуга, белемгә омтылыш тәрбияләү;китапларга карата сак караш, хөрмәт тәрбияләү. | Тәрбияви чара “Китаплар патшалыгы” |
| 30 | **Саулык- зур байлык. Минем сәламәтлегем.** | 30 март-4 апрель | 30 март- Җирне саклау көне<br>1 апрель- Халыкара кошлар көне; Композитор һәм пианист Сергей Васильевич Рахманиновның туган көне (1873-1943)<br>2 апрель- Халыкара балалар китабы көне. | Балаларда үз сәламәтлекләренә карата игътибарлылык, сак караш тәрбияләү,сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш булдыру.Балаларга сәламәтлекне саклауда табигатьнең әһәмиятен аңлату, чыныгу чаралары белән таныштыру. | Әти-әниләр катнашында спартакиада. |
| 31 | **Терек булмаган табигать<br>Галәм киңлекләре. Һаваның әһәмияте (мәт)** | 6-11 апрель | 7 апрель- Бөтендөнья сәламәтлек көне<br>12 апрель- Космонавтика көне, СССРның Җирнең беренче ясалма иярченен җибәрү көне, Россия классигы һәм драматургы Александр | Балаларда беренче очучы Ю.Гагарин белән танышу аша илебезгә карата горурлык хисләре тәрбияләү;Галәм турындагы белемнәрен системалаштыру;Кояш системасы, планеталар турында элементар белешмә бирү, алар турында күбрәк беләсе килү теләге уяту; Космонавтика көне турында белемнәрен формалаштыру;тирә-юньне, табигатьне аңларга һәм сакларга сәләтле актив, иҗади шәһес тәрбияләү. | Викторина “Галәм киңлекләре”. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Николаевич Островскийның туган көне (1823 1886) | | |
| 32 | **Куркынычсызлык. Уттан саклан.** | 13 – 18 апрель | | Ут чыгу куркынычы булган әйберләр белән сак булу сыйфаты тәрбияләү. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышуны дәвам итү, янгын чыгу очрагында үзләрен дөрес тоту күнекмәләрен ныгыту,балаларны игътибарлы булырга өйрәтү. | Куркынычсызлык кагыйдәләре буенча уен-ситуацияләр. |
| 33 | **Җир-безнең уртак йортыбыз! Планетаны саклыйбыз!Көньяк һәмтөньяк илләренең хайваннары,кошлары** | 20-25 апрель | 22 апрель-Бөтендөнья Җир көне<br>26 апрель-Габдулла Тукайның туган көне | Балаларның Җир планетасы, анда яшәүчеләр турында күзаллауларын киңәйтү. Табигатькә мәхәббәт тәрбияләү, аны кайгырту теләге тудыру.Балаларның хайваннарның яшәү шартларына яраклаша алулары турындагы,көньяк һәм төньяк илләрдәге кыргый хайваннар турында күзаллауларын формалаштыру. | “Җир-безнең уртак йортыбыз!”-рәсем күргәзмәсе. |
| 34 | **Г.Тукай безнең күңелләрдә<br>Әкияттә кунакта** | 27 апрель - 4 май | 30 апрель-Янгын сүндерүчеләр көне.<br>1 май-Яз һәм хезмәт бәйрәме | Г.Тукайның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру; балаларда Г.Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту,таныш әдәби сюжетлар буенча балаларның Г.Тукай иҗаты буенча алган белемнәрен камилләштерү;шагыйрьгә,шагырьнең иҗатына карата мәхәббәт, ихтирам хисләре тәрбияләү;Г.Тукай әкиятләре, шигырьләре аша балаларда матур әдәбият белән кызыксыну, аларны укырга теләк тәрбияләү, тырышлык, игътибарлылык, сабырлык кебек сыйфатлар тәрбияләү. | Шигырь уку бәйгесе “Тукай безнең йөрәкләрдә”. |
| 35 | **Җиңү алып килгән яз.** | 6 – 11 май | 7 май-Петр Ильич Чайковскийның (1840-1893)туган көне<br>9 май-Җиңү көне | Сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында балаларның белемнәрен арттыру;Бөек Ватан сугышы герой-лары , аларның күрсәткән батырлыклары турында күзаллауларын киңәйтү;Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкларын үстерү;балаларда Ватанга, туган якка, туган телгә мәхәббәт, патриотик хисләр, кыю һәм батыр булу теләге тәрбияләү. | "9 Май – Җиңү көне." – Обелискка чәчәкләр кую |
| 36 | **Урман-җиребезнең матурлыгы, байлыгы. Терек табигать.(Бөҗәкләр белән таныш)** | 13 – 18 май | 13 май- Кара диңгез флотына нигез салу көне .<br>15 май- рус рәссамы-рәссам һәм архитектор Виктор Михайлович | Балаларда урманга һәм аның байлыкларына сак караш тәрбияләү; кешеләр тарафыннан табигатьне сакларга кирәклеге турында нәтиҗә чыгара белү, логик фикер йөртә белү сәләтен үстерү;урман, андагы тереклек (бөҗәкләр) турындагы белемнәрен тирәнәйтү, мул табигатьнең кешетормышында әһәмиятен аңлату. | Тәрбияви чара “Урман- безнең дустыбыз”. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | Васнецовның (1848-1926)туган көне.<br>18 май- Балтыйк флотына нигез салу көне.<br>19 май- Россия балалар иҗтимагый оешмалары Көне | | |
| 37 | **Бүлмә гөлләре.**<br>**Чәчәкләр-тормыш яме. Терек булмаган табигать туфракның әһәмияте (мэт)** | 20 – 25 май | 24 май- Славян язуы һәм мәдәнияте көне | Балаларда барлык тереклек ияләренә карата шәфкатьлелек,табигатькә сак караш тәрбияләү, тикшерү, тәҗрибә үткәрү эшчәнлеге нигезендә экологик фикер йөртү, иҗади хыял сәләтләрен үстерү. Туфрак турындагы күзаллауларын киңәйтү, бүлмә гөлләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыруны дәвам итү. Бүлмә гөлләрен танып әйтә белү күнекмәләрен камилләштерү; гөлләрне үстерү, карау тәртибе турында белемнәрен ныгыту. | Кызыклы чара“Чәчәкләр балы” |
| 38 | **Тиздән җәй! Мониторинг.** | 27– 31 май | 25май-Соңгы кыңгырау | Балаларның җәй турында күзаллауны киңәйтү, белемнәрен ныгыту; табигатькә аңлы караш, экологик культура тәрбияләү. | “Хуш сөекле бакчабыз!”- бәйрәм иртәсе. |